Г.Р. Мөгътәсимова

Казан федераль университеты, Казан

# И.С. ТУРГЕНЕВ ӘСӘРЛӘРЕНЕҢ ТАТАРЧАГА ТӘРҖЕМӘЛӘРЕНДӘ ТӨС АТАМАЛАРЫ

Аннотация. В данной статье рассмотрены проблемы перевода цветообозначений в произведениях И.С. Тургенева. Проанализирована роль колоративной лексики в реализации замысла автора, вербализации авторской модальности. На основе проведенного автором исследования приводятся основные переводческие трансформации, применяемые для адекватной передачи цветообозначений при переводе художественных произведений. Анализ проводится на материале произведений И.С. Тургенева «Льгов», «Бирюк», «Певцы», «Отцы и дети» и их переводов на татарский язык.

Abstract. This article discusses the problems of translation of color-namings in the works of I. S. Turgenev. Analyzes the role colorative vocabulary in the implementation of the intent of the author, verbalization of the author's modality. On the basis of the author's researches are the main translation transformation applied to the appropriate transfer of the color-indication in the translation of works of art. The analysis is based on the works of I. S. Turgenev "Lgov", "lone wolf", "Singers", "Fathers and sons" and their translation into Tatar.

И.С. Тургенев әсәрләре төсләргә бик бай. Автор төсләрне белдергән сыйфатларны табигатьне тасвирлаганда аеруча актив куллана. Мәсәлән, ул иртәнге күк йөзен болай тасвирлый: «С самого утра перепадал мелкий дождик, сменяемый по временам теплым солнечным сиянием; была непостоянная погода. Небо то все заволакивалось рыхлыми белыми облаками, то вдруг местами расчищалось на мгновенье, и тогда из-за раздвинутых туч показывалась лазурь, ясная и ласковая, как прекрасный глаз» («Свидание»). Үзенең «Касьян» исемле әсәрендә исә көндезге күк йөзен болай күрә бөек язучы: «По ясному небу едва-едва неслись высокие и редкие облака, изжелта-белые, как весенний запоздалый снег, плоские и продолговатые, как опустившиеся паруса. Их узорчатые края, пушистые и легкие, как хлопчатая бумага, медленно, но видимо изменялись с каждым мгновением; они таяли, эти облака, и от них не падало тени» («Касьян»). Ә менә кичке күк менә болай үзгәрә: «Солнце садилось; широкими багровыми

полосами разбегались его последние лучи; золотые тучки расстилались по небу все мельче и мельче, словно вымытая, расчесанная волна…» («Льгов») . Әлеге өзекләрдәге төсләр күзне чагылдыра. Алга таба без әлеге төс атамаларын татарчага тәрҗемә итү юлларын карарбыз.

Тикшерү объекты итеп И.С. Тургеневның “Льгов”, “Бирюк”, “Певцы”, “Отцы и дети” әсәрләре һәм аларның татарчага тәрҗемә ителгән “Льгов”, “Бирюк”, “Җырчылар”, “Аталар һәм балалар” әсәрләрендәге төс атамалары алынды. Алар Ф. Әмирова, М. Гали, М. Әмир тарафыннан тәрҗемә ителгәннәр.

Рус классигы И.С. Тургенев әсәрләренә күп кенә тәрҗемәчеләр игътибарларын юнәлткән, аның әсәрләре татар теленә XIX гасыр урталарыннан ук тәрҗемә ителә башлаган. И.С. Тургенев үзе дә телләр өйрәнгән, тәрҗемәчелек белән шөгыльләнгән. Аның Флобер әсәрләрен тәрҗемә итүе мәгълүм. Әлеге тәрҗемә белән ул рус тәрҗемәсе тарихында лаеклы урынна алып тора. И.С. Тургеневның татар теленә тәрҗемә әсәрләреннән түбәндәгеләр билгеле: “Яһүди” (тәрҗемәче – С. Рахманколый, 1846), “Акчасызлык. Петербургта торучы бер яшь дворянинның тормышыннан бер күренеш” (тәрҗемәче – Г. Сәйфелмлуков, 1909), “Төтен” (тәрҗемәче – С. Рахманколый, 1909), “Беренче мәхәббәт” (тәрҗемәче – Г. Садрый, 1913), “Муму” (тәрҗемәче – З. Нуркин, 1930), “Аталар һәм балалар” (тәрҗемәче – Ф. Бурнаш, 1932), “Муму” (тәрҗемәче – Х. Хисмәтуллин, 1934), “Аучы язмалары” (тәрҗемәче – М. Гали, 1936), “Бирюк” (тәрҗемәче – М. Гали, 1941), “Аталар һәм балалар” (тәрҗемәче – М. Әмир, 1949), “Бүдәнә” (тәрҗемәче – Ф. Әмирова, 1950), “Җырчылар. Аучы язмаларыннан” (тәрҗемәче – М. Гали, 1954), “Рудин” (тәрҗемәче – М. Максуд, 1963, 2 нче басма), “Язгы сулар” (тәрҗемәче – Ф. Гайнанова һәм В. Зыятдинов, 1975), “Аучы язмалары” (тәрҗемәче – В. Зыятдинов, 1978).

Рус телендә язылган әсәрләрне татар теленә тәрҗемә итү проблемалары күп кенә тикшеренүчелар тарафыннан өйрәнелгән: Сафиуллина Ф.С. [4: 169-174], Кириллова З.Н. [1: 160-162], Мөгътәсимова Г.Р. [2: 339-342] һәм башкалар.

Рус һәм татар телләрендә төп төс атамаларының мәгънәләре охшаш. Әмма шуңа да карамастан, әлеге телләрдә сөйләшүчеләрнең төсләрне кабул итүендә

аермалар бар. Төс атамаларын тәрҗемә иткәндә исә, кайбер лексик берәмлекләрнең мәгънәләре анык булмавын да истә тотарга кирәк. Шулай итеп, матур әдәбият әсәрләрендәге төс атамаларын тәрҗемә итүдә авырлыклар барлыкка килә. Тәрҗемә ителгән матур әдәбият әсәрләренең чыганактан аерылып торуы котылгысыз.

Тәрҗемә белемендә телара лексик тәңгәллекләр проблемасы мөһим урын алып тора. Танылган галим Я.И. Рецкер чыганактагы һәм тәрҗемәдәге лексик берәмлекләр арасында мөмкин булган тәңгәллекләрне төп өч төргә бүлеп карый: үзара эквивалент, үзара охшаш, бер-берсен алмаштырып килә ала торган сүзләр [3: 156-157]. Р.А. Юсупов "Икетеллелек һәм сөйләм культурасы" хезмәтендә төрле телдәге төп мәгънәсе бердәм лексик берәмлекләрнең специфик булуы аларның эчке мәгънәви мөнәсәбәтләрендәге үзенчәлекләр белән аңлатылуын әйтә.

Тәрҗемәчеләр кулланган иң төп ысул ул – тәңгәллекләрен табып тәрҗемә итү. Мәсәлән, *Что, Петр, не видать еще? - спрашивал 20-го мая 1859 года, выходя без шапки на низкое крылечко постоялого двора на *** шоссе, барин лет сорока с небольшим, в запыленном пальто и клетчатых панталонах, у своего слуги, молодого и щекастого малого с* ***беловатым*** *пухом на подбородке и маленькими тусклыми глазенками ("Отцы и дети") - 1859 нчы елның 20 нче мае иде. *** юлы өстендәге юлаучылар йортының тәбәнәк болдырына яше кырыктан үтеп барган, яланбаш, өстенә тузанланып беткән пальто һәм шакмаклы чалбар кигән бер барин чыкты. Ул үзенең хезмәтчесенә – иягенә* ***аксыл*** *йон үскән, тулы битле, кечкенә һәм нурсыз күзле егеткә мөрәҗәгать итте. ("Аталар һәм балалар"); Над дверью избушки прибита* ***голубая*** *дощечка: эта избушка — кабак, прозванный «Притынным» *. ("Певцы") - Өйнең ишеге өстенә* ***зәңгәр*** *такта кадакланган: бу өй – «Притынь» дип йөртелә торган кабак. ("Җырчылар").* Әлеге тәңгәллекләр мәгънә бердәмлеге белән характерланалар. Тулы тәңгәллекләр тәрҗемәчеләр өчен авырлык тудырмый.

Тәрҗемәләрне тикшергәндә, тәрҗемәчеләрнең өлешчә тәңгәллекләрдән дә файдаланганнарын күрергә мөмкин булды. Мәсәлән, *Посередине кабака*

*Обалдуй, совершенно «развинченный» и без кафтана, выплясывал вперепрыжку перед мужиком в* ***сероватом*** *армяке; мужичок, в свою очередь, с трудом топотал и шаркал ослабевшими ногами и, бессмысленно улыбаясь сквозь взъерошенную бороду, изредка помахивал одной рукой, как бы желая сказать: «куда ни шло!» («Певцы»). - Аяк буыннары тотмый башлаган Обалдуй, чикмәнен салып ташлап, кабак уртасында,* ***соры*** *чикмәнле мужик каршында биеп маташа; үз нәүбәтендә мужик та, "каян килеп кая китмәгән!" дип әйтергә теләгән кыяфәттә, кулын сирәк кенә селтәп, тырпайган сакалы эченнән мәгънәсез елмаеп, йомшарган аяклары белән көчкә генә тыпырдый. («Җырчылар»).* Әлбәттә, «сероватый» сыйфатын «соры» дип тәрҗемә итүне уңышсыз дип әйтеп булмый.

И.С. Тургенев әсәрләрендә күзәтелгән төс атамаларын татарчага тәрҗемә иткәндә, төрле трансформацияләр дә кулланылган. Чыганак текстта төс сыйфаты белән бирелмәгән кайбер берәмлекләр татар теленә төс сыйфатлары белән тәрҗемә ителгән: *Выражение его смуглого с* ***свинцовым*** *отливом лица, особенно его* ***бледных*** *губ, можно было бы назвать почти свирепым, если б оно не было так спокойно-задумчиво. ("Певцы") - Әгәр ул тыныч, уйчан булмаса, үзенең* ***кара кургашын төсле*** *йөзенә, бигрәк тә* ***аксыл*** *иренenә карап, аны явыз кеше дип уйларга мөмкин булыр иде. ("Җырчылар").*

Тәрҗемәчеләр чыганакта күзәтелгән төс сыйфатларын тәрҗемәдә төшереп калдырып та биргән очраклар булуы ачыкланды: ***...серый*** *мужичок то и дело твердил в своем уголку, утирая обоими рукавами глаза, щеки, нос и бороду... ("Певцы") - ....мужик, почмакта утырган көйгә, ике җиңе белән күзләрен, яңагын, борынын һәм сакалын сөртә-сөртә... ("Җырчылар"); Его потащили к стойке; он подозвал к ней расплакавшегося* ***серого*** *мужичка, послал целовальникова сынишку за рядчиком, которого, однако, тот не сыскал, и начался пир. ("Певцы") - Аны өстәл янына китерделәр; ул елап утырган мужикны чакырып китерде; кабакчы кечкенә малаен рядчикны эзләргә җибәргән иде, ләкин ул аны тапмый керде ("Җырчылар").*

Кайбер очракта исә чыганактагы төс сыйфаты татар телендә төс мәгънәсендәге фигыль белән дә бирелә: *Моргач, весь* ***красный****, как рак, и широко раздув ноздри, язвительно посмеивался из угла; один Николай Иваныч, как и следует истинному целовальнику, сохранял свое неизменное хладнокровие. (“Певцы”) - Моргач, кысла шикелле* ***кызарынып****, борын тишекләрен киң җәеп, бер почмакта ачулы гына көлеп утыра; тик бер Николай Иваныч кына, чын кабакчыга хас булганча, үзенең һәрвакыттагыча салкын канлыгын югалтмаган. (“Җырчылар”).*

И.С. Тургенев әсәрләренең татарчага тәрҗемәләрендә бер үк сыйфат төрлечә тәрҗемә ителгән очраклар да шактый. Телләр арасында даими лексик эквивалентлар сирәк очракларда гына табыла. Даими тәңгәллек төшенчәсе лексиканың кайбер катламнарына: терминнарга, ай, көн исемнәренә, кайбер туганлык, хайван, эш кораллары атамаларына, зат алмашлыкларына карата гына кулланыла.Тәрҗемәдә кайвакыт төп нөсхәгә сүзлек буенча туры килә торган сүз кулланылмый. Төс сыйфаты бик сирәк кенә төгәл тәрҗемә итүне таләп итә, ә күпчелек очракта тәрҗемәче үз күзаллавыннан, “сүзләрнең милли үзенчәлеккә ия” булуыннан һ.б. чыгып, төсне үзгәртебрәк бирә. Нәтиҗәдә, төп нөсхә белән аерымлыклар килеп чыга. Мисалларга күз салыйк: *Усталыми шагами приближался я к жилищу Николая Иваныча, возбуждая, как водится, в ребятишках изумление, доходившее до напряженно-бессмысленного созерцания, в собаках — негодование, выражавшееся лаем, до того хриплым и злобным, что, казалось, у них отрывалась вся внутренность, и они сами потом кашляли и задыхались, — как вдруг на пороге кабачка показался мужчина высокого роста, без шапки, во фризовой шинели, низко подпоясанной* ***голубым*** *кушачком (“Певцы”) - Ахыры мин, арыган адымнар белән, Николай Иванычның торагына якынлаштым. Минем килүем балаларны гаҗәпләндерде, алар миңа текәлеп карап тора башладылар, ә этләр исә, эчләре чыгарлык дәрәҗәгә җитеп, карлыккан усал тавыш белән өрделәр һәм ахырда үзләре дә буылып йөткерергә тотындылар. Шул вакыт, кинәк, кабак ишеге төбендә озык буйлы, яланбаш, тупас йон материядән тегелгән шинельле,* ***күк*** *билбавын түбән төшереп билен*

*бәйләгән бер ир кеше күрендә (“Җырчылар”); Над дверью избушки прибита* ***голубая*** *дощечка: эта избушка — кабак, прозванный «Притынным» * (“Певцы”) - Өйнең ишеге өстенә* ***зәңгәр*** *такта кадакланган: бу өй – «Притынь» дип йөртелә торган кабак (“Җырчылар”); Толстый* ***сизый*** *голубь прилетел на дорогу и поспешно отправился пить в лужицу возле колодца (“Отцы и дети”) - Юл өстенә симез генә бер* ***күк*** *күгәрчен килеп төште һәм, ашыга-ашыга, кое янында җыелып яткан суны эчәргә китте (“Аталар һәм балалар”).* “Голубой” лексик берәмлеге сүзекләрдә теркәлгән мәгънәләренә караганда, ике төсне белдерә: зәңгәр һәм күк. Тәрҗемәче М. Гали бер үк текстта бер үк сүзне ике төрле лексик берәмлек белән биргән. Бу очракта тәрҗемәче чыганактагы төсләр палитрасын бераз гына җимергән дип саныйбыз. “Сизый” сүзе исә татар теленә “күгелҗем” дип тәрҗемә ителергә тиеш иде. Әмма рус мәдәниятендә “голубь сизый” булса, татар мәдәниятендә күгәрчен күк була.

Гомумән алганда, тәрҗемәчеләр чыганакның әдәби үзенчәлеген һәм идея-мәгънә төшенчәсен тулысынча саклаган һәм тәрҗемәне югары сыйфатлы итү өчен әдәби телебезнең барлык мөмкинлекләреннән файдаланган. Нәтиҗәдә бу әсәрләр дә чыганак кебек укыла. Тәрҗемә әсәре мактауга лаек булса да, әлбәттә, тикшеренү барышында кайбер төгәлсезлек булуы да күзгә ташланды. Тик бу кимчелекләр, асылда, чыганакның эчтәлеген бозарлык кимчелекләр түгел, ә, беренчедән, рус теленең кайбер специфик үзенчәлекләрен саф татарча бирә алмау булса, икенчедән, татар телендәге төс атамалары саны рус телендәгегә караганда күпкә ким булуга кайтып кала.

**Әдәбият**

1. Кириллова З.Н., Фәхриева Л.Х. А.С.Пушкинның “Кышкы иртә” (“Зимнее утро”) шигыренең татар теленә тәрҗемәсендә тел-сурәтләү чаралары // Сохранение и развитие родных языков в условиях многонационального государства: проблемы и перспективы: материалы V Международной научно-практической конференции (Казань, 19-22 ноября 2014 г.). – Казань: Отечество, 2014. – С. 160-162

2. Мөгътәсимова Г.Р. Л.Н.Толстойның "Анна Каренина" романындагы этнографик реалияләрне тәрҗемә итү үзенчәлекләре // Жизнь, посвященная тюркологии. – Казань: ТГГПУ, 2011. – С.339-342.

3. Рецкер Я.И. Теория перевода и переводческая практика. – Москва: Р.Валент, 2007. – С. 156-157

4. Сафиуллина Ф.С. Ф.Әмирхан прозасы рус телендә // Казан утлары. – 1976. - № 8. – Б. 169-174.